Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Кощаково авыл җирлеге

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Кощаково авыл җирлеге Званка авылы Урман, Ташлы урамнары гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

# КАРАР

19 октябрь, 2024 ел № 6

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Кощаково авыл җирлеге Званка авылы Урман, Ташлы урамнары гражданнарының 2024 елның 19 октябрендәге җыены беркетмәсе нигезендә түбәндәгеләр ачыкланды:

- җыенны уздыру өчен билгеләнгән территориядә яшәүче һәм гражданнар җыенында катнашырга хокуклы гражданнар саны 248 (ике йөз кырык сигез).
- халык җыены эшендә катнашкан гражданнарның гомуми саны 125 (йөз егерме биш).
- гражданнар җыенына кертелгән мәсьәләгә «**РИЗА**» өчен гомуми сан 125 (йөз егерме биш).
- гражданнар җыенына кертелгән мәсьәләгә «**КАРШЫ**» өчен гомуми сан 0 (ноль).

Югарыда бәян ителгәннәрдән чыгып түбәндәге карар кабул ителде:

1. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25 статьясындагы 6 өлеше нигезендә **гражданнар җыены мәсьәләсе буенча карарын**, түбәндәге мәсьәлә буенча «Сез 2025 елда Кощаково авыл җирлеге Званка авылы Урман, Ташлы урамнарында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган һәр кешедән, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш 3000 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен куллану белән килешәсезме?:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (юлны ремонтлау)» **кабул ителгән дип санарга.**

2. Әлеге карарны «Вперёд» («Алга») газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) һәм Кощаково авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында да бастырып чыгарырга (халыкка игълан итәргә).

Кощаково авыл җирлеге башлыгы З.Н. Саттарова